**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Чистопольский муниципальный район**
**Адельшинское сельское поселение**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Чистай муниципаль районы**
**Гаделша авыл җирлеге**

**422964, РТ, Чистопольский район, с.Татарское Адельшино ул.Сатдарова д.32 тел. 3-02-18**

**КАРАР**

07.03.2019 №3

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын
үз көчен югалткан дип тану турында

Чистай шәһәр прокурорының 2019 елның 25 февралендәге 02-08-02-2019 номерлы хезмәт күрсәтүнең административ регламентына протестын һәм Чистай шәһәр прокурорының 2019 елның 27 февралендәге 02-08-02-2019 номерлы 2017 елның 16 октябрендәге 18 номерлы карарына протестын карап тикшергәннән соң

КАРАР БИРӘМ:

1. Үз көчен югалткан дип таныргa:
– Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 16 октябрендәге «Юридик затларга (дәүләт муниципаль) учреждениеләргә субсидиялардән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга-товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 18 номерлы карарын;
- Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлеге башлыгының 2017 елның 7 сентябрендәге «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидиялардән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, физик затларга-товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 15 номерлы карарын.
2. Әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, игъланнар стендларында һәм такталарында элеп куюю юлы белән халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга http://chistopol.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артында калдырам.

Гаделша авыл
җирлеге башлыгы И.А. Нуретдинов